КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 18

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 апрель, 354 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясын, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Тискәре метеорологик шартлар турында мәгълүмат кертү тәртибен, мондый мәгълүматның составына һәм эчтәлегенә, аны бастырып чыгару һәм кызыксынучы затларга бирү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 2011 елның 17 ноябрендәге 899 номерлы һәм «Тискәре метеорологик шартлар чорында пычраткыч матдәләр атмосфера һавасына чыгаруларны киметү чараларына карата таләпләрне раслау турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 811 номерлы боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фаразга кул куйган вакыттан бер сәгать эчендә тискәре метеорологик шартлар барлыкка килү турындагы фаразларны электрон почта аша Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә түләүсез нигездә бирергә;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр заказы буенча законнар нигезендә шәһәр һәм башка җирлекләрдә тискәре метеорологик шартлар барлыкка килү турында фаразлар төзергә;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тискәре метеорологик шартлар барлыкка килгәндә нормалаштырылырга һәм исәпкә алынырга тиешле, Учреждение күзәтүләрендә булган торак пунктлардагы атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару чыганаклары урнашкан беренче, икенче һәм өченче категорияләрдәге объектларда хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек алып баручы юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә:»;

унберенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә тискәре метеорологик шартлар барлыкка килү чорында атмосфера һавасына зарарлы матдәләр чыгаруларны киметү чараларын килештерүне, шулай ук аларны төбәк дәүләт экология күзәтчелегендәге хуҗалык эшчәнлеге объектларында үткәрүне тикшерүдә тотуны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин